РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21.04.2016 № 495-п

Саба муниципаль районы территориясендә
реклама конструкцияләрен урнаштыру
схемасын раслау турында

«Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль закон, «Реклама турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 7 маендагы 98-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Саба муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыруны тәртипкә салу максатларында Саба муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Билгеләргә:

2.1. әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән схема, бастырып чыгарылган вакыттан, гамәли көчтә дип билгеләргә;

2.2. схеманың тәэсире яңа урнаштырылган тышкы реклама чараларына кагыла;

2.3. күрсәтелгән типтагы тышкы реклама чараларын һәм мәгълүматны билгеле бер схемаларда урнаштыру аларны урнаштыруның техник мөмкинлеге булганда гына рөхсәт ителә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары М.Р. Ишниязовка йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Гасимов